Шайхуллина, Р. Н. Чигүле читекләр белән биюләре күңелле: «Читек бизәү» мастер-классы / Р. Н. Шайхуллина // Ачык дәрес. Мәктәп. – 2024. – №10 (245). – Б. 33-34.



5.Олыласаң олыны,...(олыларлар үзеңне)
6. Оясында ни күрсә,...(очканында шул булыр)
6 нчы бирем "Үз балаңны таны "дип атала. Хәзер әниләрнең күзләре бәйләнгән килеш үз баласын танырга тиеш.

Алып баручы: Сүзне жюрига бирик. Бәйгебезнең җиңүчеләрен белик. (Җиңүчеләрне бүләкләү)
Әниләребезне бәйрәм белән тәбрик итәбез. Һәммәгезгә дә сәламәтлек, бәхет, тынычлык теләп бәйрәмебезне тәмамлыйбыз

# Чигүле читекләр белән биюләре күңелле

**Шайхуллина Руфия Нәфис кызы**
Яр Чаллы шәһәре үзәк китапханәсе

**Җиһазлау:** Музыка яңгырый, балалар керә. Бүлмә авыл өе кебек бизәлә, презентация, ноутбук, проектор, интерактив такта; сандык, төрле зурлыкта булган баш яулыклары, әдәбият дәреслекләре, рәсемнәр, татар халык киемнәре күрсәтелгән кулланмалар, калфак, түбәтәй, читек, чүәк, шәлләр, самавыр, мәкаль - әйтемнәр. Идән уртасында сугылган палас. Өстәлдә ашъяулык аның өстендә татар халкына кагылышлы матур трафаретлар. Кичәне ачып җибәргәндә матур калфаклы ике татар кызы чыга. Килгән кунаклар өстәл кырыена утыртыла.
**Максат:** – балаларда туган тел, туган йортны ярату, аның белән горурлану хисләре тәрбияләү;
– балаларны татар милли киемнәре һәм орнаментлары белән таныштыру.
– татар орнаменты мотивларын (яфрак, лалә, мәк, кыңгырау, тукранбаш, канәфер) аңлату;
– читек силуэтында орнамент мотивларыннан бизәк төзергә өйрәтү;
– мөстәкыйль рәвештә бизәк төзү сәләтен үстерү;
– клей белән пөхтә эш итүне үзләштерү.
**1 алып баручы:** Хәтерләүдән курыкмагыз сез!
Үткәнегезне онытмагыз сез.
Белегез сез ерак бабаларның,
Ничек итеп көн иткәнен...
Ни иккәнен, ни чиккәнен,
Нинди җырлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.
Р. Фәйзуллин шигыреннән өзек укыла. Шагыйрь бу юллар белән нәрсә әйтергә тели ?
**2 алып баручы:** Хәерле көн, кадерле кичәбез кунаклары! Безнең бүгенге кичәбез халкыбызның һәр милләтенә хас үзенчәлекләргә ия булган читекләрне бизәү. Әйе һәрбер кеше үз халкының үткәнең, бабайларның ничек көн иткәнен, ниләр белән шөгыльләнгәнен, гореф-гадәтләрен, йолаларын белергә тиеш. Чөнки үткәнен белмәгәннең киләчәге юк, ди халкыбыз.
- Нинди йолалар бар соң?

Йолалар бик күп булган: туй үткәрү, балага исем кушу, аулак өйләр, кунак кыз килү, кыз димләү, өй туе, солдатка озату,ат саклаулар…Бу матур йолаларны һәрвакыт сихри бизәкләр чолгап ала. Халык бәйрәмнәре, йолалары – кешене тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә. Эш шунда ки, ул бәйрәмнәрне халыкның олысы-кечесе бергәләп уздыра. Яшь буын бәйрәмдә катнашу тәртибен кечкенәдән үк өйрәнеп үсә. Һәр кеше, табигый рәвештә, үз-үзен тоту гадәтләрен үзләштерә, милли тәрбия ала. Гасырлардан-гасырга, буыннан-буынга, әби-бабайдан әти-әнигә, әти-әнидән балага үзләренең борынгы бәйрәмнәрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын югалтмыйча тапшырып килгән, һәм алар, күпмедер дәрәҗәдә үзгәреп, югалып бетә язып, безнең көннәргә дә килеп җиткән. Чулпы, беләзек, калфак, читек, сөлгеләре белән элек-электән дан тоткан безнең халык. Аларны эшләү осталык һәм түземлек таләп иткән. Кулына матур бизәкләр тоткан икенче укучы сөйли- сөйли бизәкләр тарата.
Бигрәк матур татар бизәкләре,
Җаның теләгәнчә ясап кал.
Җыр: Шәүкәт Галиев «Кунаклар».
Без әзерлибез табын,
Китереп бөтен ягын:
Уртага куйдык чәчәк,
Чәчәк янына -- чәкчәк.
Бавырсак һәм кош теле.
Ризыклар төрле – төрле:
Сумса, бәлеш. өчпочмак,
Гөбәдия һәм коймак.
Һәр кемгә чыгар өлеш:
Бар кыстыбый һәм бәлеш!
Җитешегез, кунаклар,
Кыстатмагыз, кунаклар!
Өйгә кайтып китәргә
Ашыкмагыз, кунаклар
**1 алып баручы:** Күңел сандыкларыгыз саекмасын, һәрчак тулыланып, баеп торсын!"
Матур җыр җырлый-җырлый, өстәл кырыена җыелган кунакларга матур бизәкләр таратыла.

**2 алып баручы:** Бүген без сезнең белән татар халкының милли киемнәре турында сөйләшеп алыйк. Татар милли киемнәре үзе бер гүзәл дөнья. Безнең әби бабаларыбыз киемнең килешле, күркәм һәм уңайлы булуына зур игътибар биргәннәр. Өс-баш матурлыгы, пөхтәлеге, чисталыгы безнең халык өчен әһәмиятле. Карагыз әле, балалар, менә монда безнең милли киемнәр бар (әкрен генә презентация бара). Бу киемнәрне балалар бәйрәмнәрдә сәхнәләштерелгән татар әкиятләрендә катнашканда кияләр. Алар шундый матур!

- Санап чыгыйк әле, нинди татар милли киемнәрен беләбез?

- Читек, түбәтәй, калфак, алъяпкыч, камзул, бала итәкле күлмәк.

- Әби-бабаларыбыз кием-салымга тәнне каплау, җылыту чарасы итеп кенә карамаганнар, аның килешле, уңайлы булуына да игътибар иткәннәр. Балалар, рәсемнәргә игътибар итегез әле. Осталар чиккән калфаклар, кәләпүшләр, түбәтәйләр, нәфис муенсалар, чигүле алъяпкычлар, бала итәкле күлмәкләр, камзуллар искиткеч матур! Алар барысы да матур бизәкләләр. Бизәкләрдә халкыбызның бәхет һәм матурлык турындагы уй-хыяллары, элек-электән килгән гореф-гадәтләре, иң якты хис-тойгылары чагыла.

Искә төшереп китик әле, татар орнаментында нинди мотивлар бар?

-Ләлә чәчәк, кыңгырау, кәнәфер, тукранбаш, мәк чәчәге, яфрак мотивлары бар.

- Сезнең бу мотивлар белән алъяпкыч, түбәтәй, калфак бизәгәнегез бар, ә менә бүген әйдәгез, читекләр бизибез. Читекләр бизәүче остазлар булабыз бүген без сезнең белән.

- Менә монда безнең остаханәдә бизәксез читекләр (читек силуэтлары), әзер бизәкләр. Шул бизәкләр белән читекләрне бизибез. Бизәкләрне ябыштырабыз.

Читекләр – татар халкының милли аяк киеме, итек формасында йомшак эчле каты үкчәле аяк киеме. Читекләр татарларда киң таралган һәм татар милли киеменең үзгәрешсез элементы булган. Русиядә бик популяр була һәм хәтта читләргә дә даны тарала аларның. «Читек» сүзе «чигелгән итек» сүзеннән кыскартылган дигән фикер дә бар. Соңрак көндәлек аяк киеменнән бәйрәмнәрдә кия торган чигүле читек дәрәҗәсенә менеп җитә алар! Татарларның көн аяк киемнәрендәге бизәкләр исә вак-вак кисәкләрдән җыела. Һәр бизәк үзара махсус җөй белән тоташтырыла. «Казан җөе» – икенче төрле аны «читек җөе» дә диләр – бары тик татар халкына гына хас эш алымы. Бүгенге көндә гаять четерекле, әмма шул ук вакытта үтә дә кызыклы әлеге кәсеп белән шөгыльләнергә теләүче яңа буын осталар барлыгын беләбез. Матур гадәт буенча, күнгә милли бизәкләр төшерелгән бизәнү әйберләре – беләзекләр, алкалар, муенсалар, букчалар һәм биштәрләр, декоратив мендәрләр, өс һәм аяк киемнәре эшләнә. Элеккеге вакытлардагыча, югары сыйфатлы күн эшләнмәләр кыйммәтле һәм затлы бүләкләрдән санала. Тарихка күз салсак, иң мөһим нәтиҗә шул: йөз еллап элек милли бизәкләр төшерелгән күнгә ихтыяҗ ничек зур булган булса, бүгенге көндә дә читекләр халык тарафыннан яратып сорала. Милли киемнәргә ихтыяҗ арта баруы куанычлы хәл, әлбәттә!

Ябыштыру “Читек бизәү”.

-Читекләр әзер булгач, аларны өстәлдә калдырабыз да бер-беребезнең читекләрне карап чыгабыз. Күрегез әле, нинди матур читекләр килеп чыкты! (Сорыйбыз, кемгә кайсы читек ныграк ошый)

- Булдырдыгыз, балалар, молодцы! Эш беткәч, уйнарга ярый. Әйдәгез әле, уйнап ял итеп алыйк. Татар халык уены “Чума үрдәк, чума каз” һәм матур татар бизәкләре белән бизәлгән өстәл уены «дженга» уйнатыла.

**2 алып баручы:** Сүзне йомгаклап шуны әйтәсе килә. Ата-бабаларыбызның йолаларын онытмыйк, киң күңелле булыйк, бер-беребезне кунакка чакырыйк, тәмле телебезне, уртак сыебызны кызганмыйк. Сезгә барыгызга да иминлек, исәнлек-саулык телибез!

# «МОГҖИЗАЛАР КЫРЫ» УЕНЫ

**Тумакова Наилә Минебарый кызы**
**Закирова Зилә Солтангәрәй кызы**
Чувашия Республикасы Батыр муниципаль округы Беренче номерлы Шыгырдан урта мәктәбе

**Тема:** Кошлар – безнең дусларыбыз.

**Максат:** Укучыларның безнең урманнарда, әйләнә-тирәбездә яшәүче кошларны белүләрен тикшерү; укучыларның аңлау, уйлау, фикерләү сәләтләрен үстерү; фикерләрен үз сүзләре белән әйтеп бирә белүләренә ирешү; укучыларда табигатькә, тирә-юньгә, шәфкатьле һәм